# Шаран киңлекләре

Йортыгызга иминлек һәм игелек!

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГӘЗИТ

12+

Гәзит 1935 елның 1 мартыннан чыга | https://sharanpro.ru | Җомга, 27 октябрь, 2023 ел | № 43 (10117)


• МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫНДА

## Шаран районы хакимияте башлыгы сайланды

Муниципаль район Советы депутатлары М. З. Әхмадуллинны Шаран районы муниципаль район хакимияте башлыгы итеп сайладылар

***Узган җомгада Шаран районы хакимиятенең зур утырышлар залында бишенче чакырылыш Шаран районы муниципаль район Советының 34нче утырышы булды.***



Утырышта Башкортстан Республикасы Башлыгы Хакимият җитәкчесе урынбасары И. Р. Әхмәтвәлиев, Башкортстан Республикасы Дәүләт җыелышы – Корылтай Секретариаты җитәкчесе М. А. Шәйхулов, БР финанс министры урынбасары З. З. Бакиров, республика Башлыгы Хакимиятенең муниципаль берәмлекләр белән белән эшләү буенча идарәсенең урындагы үзидарә органнары белән эш буенча бүлеге баш киңәшчесе А. Р. Басыйров, хакимият башлыгы урынбасарлары, хакук саклау органнары вәкилләре, авыл биләмәләре башлыклары катнашты.

Район Советы депутатлары ачык тавыш бирү юлы белән Марат Замир улы Әхмадуллинны бертавыштан контракт буенча Шаран районы муниципаль район хакимияте башлыгы итеп сайладылар.

Искәндәр Рәүф улы Марат Замир улын җаваплы вазифага сайлануы белән котлады, уңышлар һәм көйле эш теләде, Шаран районы идарә командасы алдында торган беренче чираттагы бурычларны билгеләде.

Марат Замир улы ышаныч белдергәннәре өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт белдерде, туган районында эшләү – икеләтә җаваплылык, дип билгеләде. "Бердәм командада барлык шаранлыларның тормыш сыйфатын яхшырту буенча бурычларны үтәү өчен эшләячәкбез", - диде Марат Замир улы.

***БЕЗНЕҢ БЕЛЕШМӘ***

Марат Әхмадуллин 1970 елның 17 июлендә Башкортстан Республикасы Шаран районы Мишәр авылында дөньяга килә. 1994 елда "физика һәм математика" белгечлеге буенча Башкорт дәүләт педагогия университетын тәмамлый, Кушнаренко районында укытучы, аннары мәктәп директоры булып эшли, 2008 – 2009 елларда Шаран районы хакимияте эшләр идарәчесе, аннары Шаран районы мәгариф бүлеге начальнигы була. Соңрак Кушнаренко районы хакимият башлыгы урынбасары, Кушнаренко районы хакимият башлыгы вазифаларын башкаручы булып эшли.

• МАТБУГАТ-2024

## "Районкага" язылыгыз һәм бүләкләр отыгыз!




Хөрмәтле гәзит укучыларыбыз!

2024 елның I яртысына гәзит һәм журналларга язылу кампаниясе дәвам итә. Яраткан басмаларга гадәттәгечә почта бүлекләре аша да, электрон рәвештә дә язылып була. Онлайн-язылу сервисыннан ***rbsmi.ru*** сайтында файдаланырга мөмкин. Моның өчен "Язылу" бүлегендә ***https://rbsmi.ru/catalog/podpiska/*** гәзит яки журналны сайлап алырга һәм аның басма яисә электрон версияләренә (шәхси кабинетта алуга) язылырга кирәк.

2024 елның I яртысына "Шаранские просторы" – "Шаран киңлекләре" район гәзитенә язылучылар арасында кыйммәтле бүләкләр уйнатылачак!

2024 елның 6 аена "Шаранские просторы" – "Шаран киңлекләре" район гәзитенә язылыгыз, квитанция күчермәләрен "Бәхетле абунәче" билгесе белән ***Шаран авылы, Үзәк урам, 14*** адресы буенча җибәрегез һәм бүләкләр уйнатуда катнашыгыз. Квитанция күчермәләре ***27 декабрьгә кадәр*** кабул ителә.

Безнең белән калыгыз! Республика, район яңалыкларыннан хәбәрдар булыгыз!

***РЕДАКЦИЯ.***

• АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ

## Чөгендер үстерүчеләр яхшы уңыш алдылар

Шаран районында шикәр чөгендере уңышын җыю тәмамлана

***"Татлы" тамырны "Р. Х. Мусин" крестьян (фермер) хуҗалыгында 200 гектарда үстерделәр. Быел уңыш яхшы булды, хуҗалыкта чөгендер алу эшен уңышлы тәмамладылар.***



*"Р. Х. Мусин" КФХ механизаторлары.*

Хуҗалык шикәр чөгендереңең "Крокодил", "Койот" һәм "Вапити" сортларын үстерә. "Крокодил" сорты начар һава торышы шартларында да тотрыклы уңыш бирә. "Койот" сортының уртача уңышы – бер гектардан 512 центнер, уртача шикәрлелеге - 17,5%. "Вапити" сортының уңышы һәр гектардан 600 центнерга җитәргә һәм уртача 16,9% шикәрлелектә булырга мөмкин.

"Татлы" тамыр җыюда тәҗрибәле механизаторлар катнашты. Аларның күбесенең хезмәт стажы 15 елдан артык. "МТЗ 15-23" чөгендер алу тракторында Гизар Якупов белән Юрий Петров эшләде, Алексей Гәрәев МТЗ-82 тракторында чөгендер яфракларын чабу эшләрен башкарды. Заһир Шакуров ("МТЗ-82"), Ришат Җиһаншин ("КамАЗ") һәм Рәүхәт Миңнеәхмәтов ("Т-150") алынган чөгендерне өемнәргә ташыдылар. Гомәр Маннанов һәм Әдис Арсланов "ЗСС-16" үзйөрешле төягече белән чөгендер төяү эшләрен башкардылар. Альберт Кашапов белән Илшат Исламов чөгендерне өемнәргә бушатутөяү эшләрендә ярдәм иттеләр. Механизаторлар өчен ике тапкыр ашату оештырылды, пешекче Зилә Маннанова, пешекче ярдәмчеләре Айгөл Заретдинова һәм Гөлүзә Габидуллина кыр хезмәтчәннәренә тәмле ашлар әзерләделәр.



*Чөгендер алу эшләре бара.*

"Шикәр чөгендеренең уртача уңышы һәр гектардан 400 центнер тәшкил итте, барлыгы 7500 тонна "татлы" культура җыеп алынды", - диде хуҗалыкның баш агрономы Фирдәвес Зарипов. "Эшкәртүдә заманча технологияләрдән файдалану нәтиҗәсендә яхшы уңыш җыеп алуга ирештек. Чөгендерне Чишмә шикәр заводына илттек. Хуҗалыкта шикәр чөгендерен 2007 елдан башлап үстерәбез. 2019 елда КФХ бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм күпьеллык культураларның элита орлыкларын җитештерү буенча орлыкчылык хуҗалыгы статусы алды", - дип билгеләде КФХ җитәкчесе, БР атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, "Башкортстанның иң яхшы чөгендер үстерүчесе-2019" Рафаил Мусин.

"Центральная МТС Туймазы филиалы Шаран бүлекчәсендә һәм "Р. Х. Мусин" крестьян (фермер) хуҗалыгында шикәр чөгендере алу тулысынча тәмамланды. "Шаранагрогаз" җәмгыяте һәм "С. А. Наумов" КФХ уңыш җыюны дәвам итәләр. Һава торышы катлаулы булуга карамастан, шикәр чөгендере эшкәртүнең интенсив технологияләрен файдалану исәбенә, район фермерлары яхшы уңыш алалар, район буенча уртача уңыш һәр гектардан 400 центнер тәшкил итә", - дип хәбәр итте Шаран мәгълүматконсультация үзәге директоры вазифаларын башкаручы Ришат Газизов.

***Руслан ХАФИЗОВ.***
***Автор фотолары.***

podpiska.rbsmi.ru

Башкортостанская информационная компания **Бүген республикада** мөһим • кызыклы • файдалы

# Озын һәм бәхетле гомер!

## «Башкортстанда озын гомерлелек» программасы ничек эшли?

***Өч ел элек республикада уникаль проект — «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» программасы барлыкка килде. Аның ярдәмендә өлкән буын кешеләре актив рәвештә төбәк буйлап сәяхәт итә һәм хәтта чит илләргә дә сәфәр кыла***

### «БАШКОРТСТАНДА ОЗЫН ГОМЕРЛЕЛЕК» ПРОГРАММАСЫНДА КЕМНӘР КАТНАША АЛА?



- ✓ Сез Башкортстанда яшисез
- ✓ Сезгә 55+ (хатын-кызлар) һәм 60+ (ир-атлар)
- ✗ Пенсионер (мәҗбүри түгел, программа өлкән яшьтәге эшләүче кешеләр өчен дә гамәлдә)

**Кая мөрәҗәгать итәргә?**

- ✓ «Башкортстанда озын гомерлелек» сайтында үзаллы теркәлергә. «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» бүлеген ачарга, датаны һәм юнәлешне сайларга.
- ✓ Үзегезнең шәһәр яки район хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә

**Күпме тора?**

- ✓ Бушлай — Башкортстан буйлап сәяхәтләргә
- ✓ Өлешчә түләүле — республикадан читтәге сәяхәтләргә

**Турга нәрсәләр кирәк?**

- ✓ Уңайлы автобуста хәрәкәт итү, озата баручы гид, экскурсияләр, игълан ителгән очракта — осталык дәресләре. Чит ил юнәлешләрендә — шулай ук, очу, туклану һәм яшәү урыны.

**Программада никадәр еш катнашырга мөмкин?**

- ✓ Елына бер тапкыр

Валерия Любина.

### «КҮЗЛӘРЕ ЯНЫП ТОРСЫН ӨЧЕН»

Бу проект мотлак илнең иң матур төбәкләренең берсе булган Башкортстанда туарга тиеш иде. Республика зур, анда байтак истәлекле урыннар бар, әмма күп кенә эшләүче кешеләрнең анда барырга вакыты җитми. Ә олы яшьтә, буш вакыт барлыкка килгәч, сәяхәтне оештыруда кыенлыклар туа.

Пенсионерларга уңайлы сәяхәт итәргә ярдәм итүче яңа проект булдыру идеясен төбәк Башлыгы Радий Хәбиров тәкъдим итте. Аның сүзләренчә, «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» программасының ике максаты бар: беренчесе — кешенең гомерен озайту, икенчесе — күзләр янсын, энергия, сәламәтлек булсын, кеше сәяхәт итә һәм яңа күнекмәләр үзләштерә алсын өчен тормыш сыйфатын яхшырту.

— Гаҗәп, әмма кайвакыт шулай да була: гомер буе Уфада яшәгән һәм республика файдасына эшләгән кешеләр бер тапкыр да Җилемнең һәм Торатау шиханының матурлыгын, «Изге куаклар» монастырен һәм Нарыстауны, Башкортстанның шифалы чишмәләрен һәм тарихи һәйкәлләрен күрмәскә мөмкин. Шул ук вакытта, гомер буе республика районнарда эшләгән халыкның күпчелеге Уфада булмаган, Ленин урамында йөрмәгән, Салават Юлаев һәйкәлен күрмәгән. «Башкортстанда озын гомерлелек» программасы бу гаделсезлекне төзәтергә һәм инде пенсиядәге кешеләргә хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә, — диде Радий Хәбиров.

### КАТНАШУЧЫЛАР САНЫ ЕЛЫНА 10 МЕҢНӘН 20 МЕҢГӘ КАДӘР АРТТЫ

Баштан ук «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» программасы зур популярлык казанды. Пенсионерларның юнәлешләрне сайлау мөмкинлеге бар: телисең икән — бу шәһәр буйлап йөрү, яисә табигать паркына сәфәр, атларда йөрү яки дару үләннәре җыю була ала, ә бәлки, сез изге урыннар буйлап сәяхәт итүгә өстенлек бирерсез. Шулай ук, бүген республикада бик күп чаралар уза, анда «көмеш» яшьтәге кунакларны һәрвакыт шатланып каршы алалар. Мәсәлән, Бөредә — «Вакыт елгасы» тарихи реконструкция фестивале, Баймакта — «Башкорт аты», Бүздәк районында — «Бәлешфест» һәм башка бик күп чаралар.

Проектның популярлык алуына бәйле рәвештә, аны эшләтеп җибәргәннән соң бер ел үткәч, төбәк җитәкчесе Радий Хәбиров программа бюджетын икеләтә арттырырга кушты. Шул рәвешле, «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» экскурсия маршрутлары белән хәзер 10 мең кеше генә түгел, ә елына 20 мең кеше файдалана ала.

### ЧИТ ИЛГӘ ЧЫГУ

«Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» программасында катнашучылар өчен Башкортстан буенча барлык сәяхәтләр түләүсез. Туристларны гид озатып йөри, аларны уңайлы автобус хезмәтләндерә. Экскурсия пакетына, шулай ук, туристны страховкалау, музейларга бару, осталык дәресләре керә. Сәяхәтләр бер көнлек, ялкытмый, шуңа күрә алар 300 километр радиусta планлаштырыла.

Быел «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» программасында катнашучылар беренче тапкыр чит илгә дә барды. Проектта катнашучыларның Белоруссиягә һәм Абхазиягә бару мөмкинлеге барлыкка килде. Шунысын да билгеләргә кирәк, бу турлар инде бер көнлек кенә түгел һәм алар өчен түләргә кирәк. Беларуська бер атналык сәфәр 26500 сумга төшәчәк, республика 15 мең сумны өстәп түли. Бу суммага самолетта очу, яшәү урыны, иртәнге аш, экскурсияләр керә. «Башкортстанда-Белоруссиядә озын гомерлелек» проекты бик зур популярлык белән файдалана, күрше дәүләткә быел 1300дән артык кеше сәфәр кылыр, дип планлаштырыла.

«Башкортстанда-Абхазиядә озын гомерлелек» проектына килгәндә, ул әлегә тест режимында эшли. Шушы көннәрдә Уфага тәүге 46 турист кайтты. Аларга биш көнлек юллама 28500 сумга төшкән, тагын 15 мең сумны республика өстәп түләгән. Туристлар Гаграда, Рица күлендә, Яңа Афонда булган, Сталин дачасын һәм Абхазиянең башка истәлекле урыннарын караган.

— Бу — республиканың мондый турларны оештыруда икенче тәҗрибәсе. Беренчесе, «Башкортстанда-Белоруссиядә озын гомерлелек», зур популярлык белән файдалана. Хәзер, икенче юнәлешнең никадәр кирәклеген аңлар өчен, Абхазиядә булган кешеләрнең бәяләмәләрен өйрәнәбез, — дип язды социаль челтәрләрдә Радий Хәбиров.

Чикләрне киңәйтеп, республика өлкән яшьтәге кешеләрнең сәяхәтләрен оештыру өчен яңа кызыклы маршрутлар эзләүне дәвам итә. Хәзерге вакытта «Башкортстанда озын гомерлелек. Туризм» проекты кысаларында Казахстанга туристик программалар әзерләү өстендә эш бара.

Материалларны «Башкортстан Республикасы» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе редакциясе әзерләде. Язмалар буенча тәкъдимнәрегезне axmetshina.v@rbsmi.ru адресына җибәрегез, телефон: (347) 272-92-61.

podpiska.pochta.ru

• БЕЗНЕКЕЛӘР БУЛДЫРА!

# Русиянең иң яхшы тәрбияче ярдәмчесе Шаран районында эшли

***Шаран авылы “Теремок” балалар бакчасы тәрбияче ярдәмчесе Мелине Саргсян “Лучшая няня Росии” II Бөтенрусия һөнәри осталык конкурсының төбәк этабында “Лучшая няня “особого ребенка” номинациясендә III урынны алды.***



*Мелине Саргсянны муниципаль район хакимияте башлыгы Марат Әхмадуллин котлады.*

“Солнышко” төркеменә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бала йөри, ә төркемдә барлыгы 26 бала. Мелине Нверовна тәрбияче Гөлназ Исмәгыйль кызы Бүләккуловага эштә ярдәм итә, үзенчәлекле баланың “икенче әнисе” булды. Бала аңа тулысынча ышана, аны ярата.

“Без аның белән көне буе бергә. Тәрбияче ярдәмчесе балаларны яратырга, белемле булырга тиеш. Тәрбияләнүчеләремнең рәхмәтле карашы – минем өчен иң зур бүләк”, - ди Мелине.

Мелине Нверовна – ике бала тәрбияләүче яшь әни, ул балаларны, үзенең эшен бик ярата.

“Иртән эшкә барасың килеп торса, син бәхетле кеше”, - дип исәпли ул. Балалар бакчасы коллективында аны хезмәт сөючәнлеге, башкаручанлыгы, пөхтәлеге һәм игелеклелеге өчен яраталар. Жюри әгъзалары аның эшенә, үзенең көндәлек эше турында ихлас сүзләренә югары бәя бирделәр.

Мелине Нверовнаны югары бүләгә белән котлыйбыз, алдагы конкурсларда яңа җиңүләр һәм яраткан эшендә уңышлар телибез.

*Маргарита ӘХМӘТОВА.*
*Фото ачык чыганаклардан алынды.*

• ҖИҢҮ ӨЧЕН!

# Якыннары тыныч күк йөзе астында яшәсеннәр өчен

Бурсык авылына “Турбо” позывнойлы яугир махсус хәрби операция зонасыннан отпускка кайтты

***Ул 1987 елда Саратов өлкәсе Романовский районы Мордовский Карай авылында дөньяга килә. 2005 елда Мордовокарай урта мәктәбен тәмамлап, Саратов шәһәре 52 санлы һөнәр училищесына пешекче булырга укырга керә. Ике елдан соң егетне армиягә алалар, ул Ингушетия Республикасы Назрань шәһәрендә Төньяк Кавказ хәрби округы разведка ротасында хезмәт итә.***

Демобилизацияләнгәннән соң Д. Саратов өлкәсе Балашов шәһәрендә “777” ресторанында пешекче булып эшли. Аннары вахта ысулы белән “Русское море” җәмгыятенең Мәскәү филиалында хезмәт куя. Аның белән бер цехта булачак тормыш иптәше дә эшли. Бурсык авылында аның апасы яши, яшьләр аның янына кунакка кайтып йөри башлыйлар. 2019 елда авылда йорт сатып алалар һәм шунда яшәргә калалар. Аларга Шаран районының табигате бик ошый.

2022 елның сентябрендә Дмитрий махсус хәрби операция зонасына мобилизацияләнә. “Повестка килгәч, тормыш иптәшем минем өчен бик борчылды, безнең улыбыз үсеп килә, аңа ике яшь тә өч ай. Тормыш иптәшемә барысын да аңлата алдым, ир-егет Туган илен якларга тиеш”, - ди яугир “Турбо”. Саратов шәһәрендә хәрби әзерлек вакытында, хатыны ерак юл үтеп, аның янына килә, монда алар никахларын теркиләр.

Махсус хәрби операция зонасында “Турбо” артиллерия частендә хезмәт итә. Отпускка икенче тапкыр кайтуы, беренчесе майда була. Яугир Дүртөйле мәктәбе укучылары белән очраша, тормыш иптәше белән бергә Саратов шәһәренә туганнары һәм



*“Турбо” улы белән.*

якыннары янына барып кайта. “Өйдә эш күп җыелган, отпуск көннәрендә хуҗалыкны тәртипкә китердем, өй түбәсен ремонтладым, гаиләмә кышка утын әзерләдем. Мин Бурсык авылы старостасы Ильяс Нигъмәтуллинга рәхмәтлемен, ул утын кисте, аның ярдәменнән башка авыр булыр иде, безгә ярдәм күрсәткәннәре өчен авыл Советы хакимиятенә рәхмәт”, - ди “Турбо”. Шушы көннәрдә яугирнең кыска сроклы ялы тәмамланды, һәм ул махсус хәрби операция зонасына китте. Китәр алдыннан “Турбо”: “Улымның тыныч күк йөзе астында үсүен телим, сугыш афәтен күрергә туры килмәсен. Мин – әти һәм ир, якыннарымны якларга тиешмен”, - диде.

*Руслан ХАФИЗОВ.*
*Фото ачык чыганаклардан алынды.*

• ПРОФСОЮЗЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕ

# Хезмәткәрләр хокукларын яклауда

Мәгариф хезмәткәрләре хезмәт хокуклары буенча көнүзәк сорауларга җаваплар алдылар

***1 санлы Шаран мәктәбендә РФ мәгариф һәм фән хезмәткәрләре профсоюзы республика оешмасының территориаль, башлангыч оешмалары рәисләре, Бакалы, Бүздәк, Чакмагыш һәм Шаран районнары белем бирү оешмалары, үзәкләштерелгән бухгалтерияләр, мәгариф бүлекләре җитәкчеләре семинары булды.***



*Раил Газизов чыгыш ясый.*

Шаран районы муниципаль район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Гүзәл Аксанова, район мәгариф бүлеге начальнигы вазифаларын башкаручы Михаил Пастухов сәламләү сүзләре белән чыгыш ясадылар. Алар Шаран районы, район мәгариф системасы турында сөйләделәр һәм семинар эшендә уңышлар теләделәр. Чараны Шаран районы мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмасы рәисе Ирина Никитина алып барды. РФ мәгариф һәм фән хезмәткәрләре профсоюзы Башкортстан оешмасы рәисе Раил Газизов мәгариф хезмәткәрләренең күпчелеге профсоюз әгъзалары булуын билгеләп үтте.

Мәгариф хезмәткәрләре профсоюзының социаль-икътисади мәсьәләләр буенча республика комитеты секретаре Ирина Меликова хезмәткә түләү мәсьәләләре хакында сөйләде. Хәзерге моментта педагогларга хезмәт хакы түләүнең нечкәлекләре күп, бу аеруча стимуллаштыру түләүләренә кагыла. Спикерга белем бирү оешмалары директорларына, лагерь сменалары вакытында ел әйләнәсенә эшләүче “Бригантина” савыктыру лагере тәрбиячеләре һәм вожатыйларына түләүләр турында сораулар бирделәр.

Мәгариф хезмәткәрләре профсоюзы республика комитеты баш хезмәт инспекторы Станислав Яруллин мәгариф өлкәсендәге хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм хәзерге шартларда алар белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында сөйләде. Ул алдан тарификацияләү, хезмәт килешүе, педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт мөнәсәбәтләре үзенчәлекләрен җайга салучы хокукый база нормативларында үзгәрешләр h.б. хакында хәбәр итте. Семинарда катнашучылар эчке уртак эшчәнлек, берьюлы ике сыйныфта җитәкчелек, аттестация, педагогның документлар эшчәнлеге турында көнүзәк мәсьәләләр турында сораулар бирделәр. Станислав Рашит улы барлык сорауларга җентекле һәм аңлаешлы җаваплар бирде.



*Сергей Петров бүләк ала.*

Чара ахырында Раил Газизов лаеклы бүләкләр тапшырды. 1 санлы Шаран мәктәбе коллективы БР Гаилә, хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгы Рәхмәт хаты алды. Социаль партнерлыкны үстерү өчен 1 санлы Шаран мәктәбе директоры Сергей Петров, “Батыр” балалар бакчасы мөдире Нина Царькова, Сакты мәктәбе директоры Святослав Гәрәев, Шаран авылы балалар иҗаты һәм спорт үзәге директоры Салават Хөсәенов, Чалмалы авылы “Ромашка” балалар бакчасы башлангыч профсоюз оешмасы рәисе Глүзә Кәлимуллина, Сакты мәктәбе профсоюз оешмасы рәисе Альберд Исламбуратов Башкортстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмасы мактау грамоталарына лаек булдылар.

Шаран авылы балалар иҗаты һәм спорт үзәге башлангыч профсоюз оешмасы рәисе Клара Биккинина “БР профсоюз федерациясенә 100 ел” юбилей медале белән бүләкләнде.

Бакалы, Бүздәк, Чакмагыш һәм Шаран районнары мәгариф системасы вәкилләре күп файдалы әйберләр белделәр һәм педагогларга хезмәткә түләү системасы буенча көнүзәк хәбәрләр алдылар, иң мөһиме – реском хезмәткәрләре мәгариф хезмәткәрләре хокукларын югары дәрәҗәдә яклыйлар.

*Маргарита ӘХМӘТОВА.*
*Автор фотолары.*

podpiska.pochta.ru

• СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУНЫ МОДЕРНИЗАЦИЯЛӘҮ

# Медицина ярдәменең сыйфаты арта

Шаран үзәк район дәваханәсенә заманча эндоскопик җиһаз сатып алынды

***Ашказаны-эчәк, авыз куышлыгы, бугаз һәм сулыш органнары авыруларын диагностикалау өчен федераль һәм республика бюджетлары акчаларына заманча ике аппарат: HD-500 эксперт видеоэндоскопия системасы һәм “OLYMPUS CV-170” гастро- һәм бронхоскоп сатып алынды.***

“Яңа җиһаз сатып алу белән дәваханәнең эндоскопия хезмәте авыруларны даигностикалауның яңа дәрәҗәсенә чыкты. Аппаратлар авыруларны башлангыч стадиядә ачыкларга ярдәм итә”, - диде Шаран үзәк район дәваханәсе табиб-эндоскописты Азат Әхмадуллин.

HD-500 эксперт видеоэндоскопия системасы киң спектрда тикшерүләр үткәрергә, шул исәптән онкологик шешләр барлыкка килүне иртә стадиядә ачыкларга ярдәм итә. Аппарат колоноскопия, ягъни эчәклеккә диагностик тикшерүгә каралган. Ә “OLYMPUS CV-170” гастро- һәм бронхоскобы авыз куышлыгы, бугаз, бронхлар, үңәч, ашказаны һәм уникеилле эчәк тикшерүләре өчен билгеләнә.

Медицина ярдәме сыйфатын арттыру шаранлыларның сәламәтлек торышын яхшыртуга ярдәм итәчәк.

*Руслан ХАФИЗОВ.*
*Фотода: А. Әхмадуллин.*



• УРЫНДАГЫ БАШЛАНГЫЧЛАРНЫ ХУПЛАУ ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ

# Авыл кешеләренең проблемаларын хәл итү өчен

Мичурин авылында Урындагы башлангычларны хуплау программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән балалар уен мәйданчыгы ачылды

***2022 елның декабрендә Мичурин авылында халык җыелышында балалар уен мәйданчыгы төзү өчен тавыш бирделәр. Балалар уен мәйданчыгын Чалмалы авылыннан шәхси эшкуар Марсель Мөхәммәтов кыска срокларда төзеде. Әкияти бүләк өчен авыл яшьләре өлкәннәргә рәхмәт белдерделәр, шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар.***



*Мичурин авылы балалар уен мәйданчыгы.*

“Балалар уен мәйданчыгы авыл Советында Урындагы башлангычларны хуплау программасы кысаларында төзелгән беренче мәйданчык” – дип билгеләде Мичурин авыл Советы авыл биләмәсе башлыгы Владимир Корочкин. Владимир Николаевич Мичурин авыл биләмәсенең актив кешеләре Николай Яковлевка, Нина Кәримовага, Богансаз авылында туып-үскән Артем Хәкимовка, эшкуарлар Марсель Мөхәммәтовка, Едгор Хусеновка һәм Алия Фәрхетдиновага рәхмәт хатлары тапшырды. Артем Хәкимов 31000 сум, Алия Фәрхетдинова27000 сум, Едгор Хусенов 15000 сум, Марсель Мөхәммәтов 10000 сум акча бирде. Шулай ук “Базы” авыл хуҗалыгы кооперативы директоры Вадим Соколов, “Шаран керамика комбинаты” җәмгыяте директоры Сергей Баранов, “Водоканал” МУП директоры Альфред Габдуллин, эшкуарлар Раил Зиннуров, Анатолий Васильев, Станислав Капитонов, Олег Димитриев, Илгиз Хәлиуллин, Лидия Әхмәдиева һәм башкалар финанс ярдәме күрсәтәләр.

Шаран районы муниципаль район Советы секретаре Рамил Нуриев һәм район финанс идарәсе начальнигы Наил Хәснуллин, шәхси эшкуар Марсель Мөхәммәтов бәйрәмнең почетлы кунаклары булдылар.



*Балалар мәйданчыгы ачылу тантанасы.*

“Урындагы башлангычларны хуплау программасы эшли, быел Шаран районында конкурс сайлап алу нәтиҗәләре буенча җиде проект тормышка ашырыла”, - диде Рамил Нуриев. Инициатива төркеме рәисе Әлфинә Низаева һәм инициатива төркеме әгъзалары Фидрат Тәхвәтшин, Филүс Сәмигуллин муниципаль район Советы рәхмәт хатларына лаек булдылар. Алар балалар уен мәйданчыгы алдында тротуарлар ясадылар, тротуар плитәләрен урындагы аграрий Азат Айдагулов бирде.

“Урындагы башлангычларны хуплау программасы Башкортстанда 2006 елдан гамәлдә, Шаран районы анда 2016 елдан катнаша башлады. Шушы еллар эчендә конкурста авыл биләмәләрендә 38 миллион сум күләмендәге 37 проект җиңеп чыкты. Моңа авыл биләмәләре хакимиятләре башлангычлары, урындагы халык һәм иганәчеләр ярдәме белән ирешелде. Мичурин авыл Советы якты үрнәкләрнең берсе булып тора, 8 ел эчендә монда җиде проект тормышка ашырылды”, - диде Рамил Нуриев. Подряд бригадасы җитәкчесе Марсель Мөхәммәтов та кунакларның котлауларына кушылды, ул халыкка сәламәтлек, матур тормыш теләде.



*Владимир Корочкин Марсель Мөхәммәтовка Рәхмәт хаты тапшыра.*

“Халык 180 мең сум акча җыйды, иганәчеләр 200 мең сум акча бирделәр, республика бюджетыннан 1 млн. 100 мең сумнан артык, ә авыл биләмәсе бюджетыннан 400 мең сум акча бүлеп бирелде”, - диде инициатива төркеме рәисе Әлфинә Низаева.

Тасма кисү хокукы инициатива төркеме рәисе Әлфинә Низаевага, инициатива төркеме әгъзасы Филүс Сәмигуллинга һәм Мичурин авыл мәдәният йорты каршында эшләп килгән “Соловушка” балалар вокаль ансамбле тәрбияләнүчесе Тамерлан Вәлиуллинга бирелде, ул яңа балалар уен мәйданчыгына беренче булып бәя бирде.

“Урындагы башлангычларны хуплау программасы ярдәмендә 2016 – 2017 елларда Яңа Юмаш авыл клубының түбәсен алыштырдык, яңа ишекләр һәм тәрәзәләр куйдык, музыкаль җиһазлар сатып алдык, 2018 – 2019 елларда Три Ключа мәктәбе түбәсен һәм тәрәзәләрен алыштырдык, 2020 елда Иске Торбый авылы зиратын яңа койма белән әйләндереп алдык, ә 2022 елда Рождественка авылында спорт мәйданчыгы төзелде. Авыл биләмәсендә хәл ителмәгән бурычлар күп, Урындагы башлангычларны хуплау программасына зур өметләр баглыйбыз, чөнки әлеге программа авыл поблемаларын хәл итүдә нәтиҗәлелеген раслады”, - дип билгеләде Владимир Корочкин.



*Яшь мичуринлылар чыгыш ясый.*

*Руслан ХАФИЗОВ.*
*Автор фотолары.*

• КАҺАРМАННАРГА - МӘҢГЕЛЕК ХӘТЕР ҺӘМ ДАН!

# Артур Сәетов истәлегенә

Шаран авылы физкультура-спорт комплексында махсус хәрби операция барышында һәлак булган Артур Сәетов истәлегенә мини футбол буенча районара ярышлар үтте

***Ярышлар быел икенче тапкыр узды. Анда Шаран авылыннан, Туймазы һәм Октябрьский шәһәрләреннән, Чакмагыш һәм Иске Томбагыш авылларыннан җиде футбол командасы катнашты.***

Шаран районы муниципаль район хакимияте башлыгы Марат Әхмадуллин, “Ватан сакчылары” Дәүләт фонды филиалы җитәкчесе Римма Гобәйдуллина, һәлак булган Ватан сакчылары гаиләләренең Гомумрусия иҗтимагый оешмасы БР буенча төбәк бүлеге вәкиле Фәридә Мөхәммәтҗанова, Уфа шәһәреннән махсус хәрби операция катнашучысы (позывное “Старый”) ярышларның почетлы кунаклары булдылар.

“Мини футбол буенча районара ярышлар – каһарман якташыбыз Артур Сәетов истәлегенә хөрмәт билгесе. Без аны беркайчан да онытмаячакбыз”, - дип билгеләде Марат Әхмадуллин үзенең сәламләү сүзләрендә. Артурның әтисе Виталий Сәетов ярышларда катнашучыларга гадел җиңү теләде. “Минем улым ачык күңелле, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер кеше иде, ул Туган илен чиксез яратты. Мини футбол буенча ярышларга килгән егетләрне күрүемә бик шатмын. Артур турында хәтерне саклавыгыз өчен рәхмәт”, - диде Виталий Александрович.



*Чараның почетлы кунаклары.*

Командалар төркем эчендә әйләнә системасы буенча матчлар үткәрделәр. Шаран авылы “Мастер” футбол командасы “А” төркемендә керде. Уенчыларыбыз Иске Томбагыш командасы белән очрашты һәм аны 5:0 исәбе белән җиңде, ә Октябрьский шәһәре “Метеор” футбол командасы 2:0 исәбе белән, чакмагышлыларны 1:0 исәбе белән җиңде. Шулай итеп, Шаран командасы үз төркемендә лидер булды һәм ярымфиналга юллама алды. Ярымфиналда “Мастер” футбол командасы Туймазы шәһәре “Маркиз” командасы капкасына ике туп кертеп, көндәшләреннән өстенрәк булып чыкты. Туймазы шәһәре “Сәлам” футбол командасы Октябрьский шәһәре “Метеор” командасын 2:1 исәбе белән җиңде. Өченче урын өчен Шаран авылы “Мастер” футбол командасы белән Октябрьский шәһәре “Метеор” командасы көрәште. Киеренке уенда Шаран футболчылары көндәшләрен 5:1 исәбе белән җиңделәр һәм өченче урынны алдылар. Туймазы шәһәре “Сәлам” һәм “Маркиз” командалары беренче урын өчен ярыштылар, нәтиҗәдә “Сәлам” җиңде һәм ярыш лидерлары өчлеген җитәкләде, ә “Маркиз” футбол командасы икенче урынга чыкты. Барлык җиңүчеләр һәм призерлар дипломнар, кубоклар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр. Җиңүче “Сәлам” футбол командасы икенче ел рәттән мини футбол буенча районара ярышларның күчмә кубогына ия булды. Туймазы шәһәре “Сәлам” ФК уенчысы Данил Вафин иң яхшы һөҗүмче, Туймазы шәһәре “Маркиз” футбол командасыннан Марат Сабиров иң яхшы капкачы булып танылды, ә Шаран авылы “Мастер” футбол командасыннан Артур Шәйхиев “Иң яхшы сакчы” номинациясендә билгеләнде. “А. Сәетов истәлегенә мини футбол ярышларында катнашу минем өчен һәм командам өчен намус эше булып тора. Артур Витальевич – минем якташым, ул махсус хәрби операция зонасында батырларча һәлак булды. Аның батырлыгы безнең барыбыз өчен дә үрнәк булып тора”, - дип уртаклашты А. Шәйхиев. Виталий Сәетов ярышларның популярлык алуын билгеләп үтте, футбол командаларының быелгы очрашуы тагын да кызыклырак булды, катнашучылар саны да арткан.



*Уен күренеше.*

Һәр елны Артур Сәетов истәлегенә мини футбол буенча районара ярышлар үткәрү Артурның әнисе ягыннан туганы Зинур Бискуновның идеясе. Ул БР атказанган укытучысы, Бөрҗән районы Әбделмәмбәт урта мәктәбендә физкультура укытучысы булып эшли. “Туганымның улы футбол уйнарга ярата иде, бу Артурның бөтен тормышы кебек ашкынулы һәм якты уен”, - диде Зинур Гомәр улы.

***Руслан ХАФИЗОВ.***
***Фотолар ачык чыганаклардан алынды.***



*“Мастер” ФК ярыш кунаклары белән.*

• РАЙОН ТАРИХЫ - КЕШЕЛӘР ЯЗМЫШЫНДА

# Чын патриотлар булып үстеләр

Һәр кешенең үзе туып-үскән, беренче адымнарын ясаган иң кадерле җире бар

***Минем өчен ул - Акбарыс авылы. Ул Башкортстанның гүзәл почмагына урнашкан... Тирә-якта урманнар, сөзәк таулар, шифалы салкын сулы чишмәләр. Кышын бар табигать ак тун кия. Бу әкияти матурлык! Җәен тагын да матуррак: бөтен җирдә яшеллек, күпме дару үләннәре, җиләкләр, чикләвек!***

Бөек Русиябез шулкадәр матур, табигать байлыклары күп. Әмма иң мөһим байлыгы – кешеләр. Һәр русияле күршесен ашата, киендерә ала, егылганга торып басарга ярдәм итә, соңгы күлмәген бирә, әмма туып-үскән җирен беркайчан да бирми. Ул аны ахыргача кадәр яклый. Һәрвакыт шулай булган. Безнең җиребезгә күп тапкырлар дошманнар килгәннәр.

Беренче Бөтендөнья сугышы башланган. Русия армиясе составында акбарыслылар да көрәшкәннәр. Бу сугышта башкорт кавалериясе үзен чын көч итеп күрсәтә. Агаем (әтиемнең абыйсы) Митрофан Урсаев башкорт кавалериясендә хезмәт иткән, фронтта һәлак булган, икенче агаем да (әнинең абыйсы) һәлак булган. Әти исән-сау әйләнеп кайткан.

Русия сугышсыз озак яшәми. Октябрь революциясе, гражданнар сугышы башлана. Көнбатыш күршеләр һәм океан арты “дуслары” сугыш белән керәләр, яшь Совет республикасын юкка чыгарырга телиләр. Әтиемнең энесе легендар Чапаев дивизиясендә хезмәт итә. Әти Чехословакия фетнәсен бастыруда катнаша. Ул яралана, Омск шәһәрендә госпитальдә дәвалана. Гражданнар сугышы тәмамлангач агаем гаилә кора, Дүртөйле районында яшәп кала, ә әти Акбарыс авылына кайта.

Гражданнар сугышыннан соң совет халкы илне торгыза, тормыш җайлана башлый. Ләкин тагын сугыш уты кабына. Бөек Ватан сугышы башлана. Совет халкы Туган ил сагына баса. Завод-фабрикаларда, колхоз һәм совхоз басуларында бөтен авырлык хатын-кызлар һәм үсмер балалар җилкәсенә төшә.

Минем өчен намус, гаилә беренче урында, әтием, әнием минем өчен барыннан да мөһим. Әти Ржев янында һәлак була. Әниебез укый-яза белмәде, әмма безгә дәрес тәрбия бирде. Сугыш вакытында ул ат караучы булып эшләде, кул белән чәчте, урды. Фидакарь хезмәте өчен “Хезмәт батырлыгы өчен” медале белән бүләкләнде. Мин беркайчан да аның “булдыра алмыйм, эшләмим, арыдым” дигәнен ишетмәдем. Ул барысын да эшли белә иде: җеп эрләде, тукыды, ямады, текте, безгә ашарга әзерләде. Иң мөһиме – әни бездә хезмәт сөючәнлек тәрбияләде, һәр эш урынында гадел хезмәт итәргә, таләп ителсә, Ватан сагына басарга кирәклеген аңлатты. 1973 – 1974 елларда абый (хәрби) хезмәт бурычы буенча ике тапкыр Сириядә булды. Аның хәрби билетында “Ватанга тырыш хезмәте өчен хәрби формама киеп йөрергә хакы бар” дигән язма бар иде.

Әти яклап дәү әтием укый-яза белмәгән авыл кешесе иде, әмма чын патриотлар – Ватан сакчылары үстергән. Уллары Беренче бөтендөнья сугышында да (олы улы һәлак була), Гражданнар сугышында да катнашкан. Бөек Ватан сугышында биш Урсаев - өч улы һәм ике оныгы (Г. М. Урсаев, Т. М. Урсаев) фронтка китә. Ике улы (әти һәм Гражданнар сугышында Чапаев дивизиясендә хезмәт иткән агаем) һәлак була. Дәү әтинең ике оныгы һәм кече улы җиңү белән кайта.

Кызларының сүзләре буенча, дәү әтием Милгуҗа Урсаев уллары турында горурланып: “Лаеклы уллар үстердем: өйдә дә ярдәм иттеләр, авыр вакытта илне дә якладылар”,- дип сөйләгән.

Һәм бүгенге көндә дә яшь буынның Ватанны лаеклы саклаганын күрәбез. Каһарманнарга дан!

***Зинаида СЫРТЛАНОВА-УРСАЕВА,***
***48 ел эш стажына ия педагог.***
***Октябрьский шәһәре.***

• ЯРАТЫП СӨЙЛИМ

# Ягымлы, киң күңелле кеше

Чираттагы көз Шаран авылында яшәүче Фәүзәнә Фәрхетдинованың юбилей көзе

***Әнием, газиз әнкәем! Шушы гади генә сүзләргә никадәр мәгънә салынган. Дөньяга килгәч тә без аның ягымлы тавышын ишетәбез.***

Әни безне йөрергә, сөйләшергә, дөньяны яратырга өйрәткән кешебез. Без авырганда күпме йокысыз төннәр үткәргән ул?! Әни безнең белән бәйле бөтен нәрсәне хәтерли. Ул безне ничек бар, шулай кабул итә һәм ярата. Әнием, газиз әнкәем! Без кечкенә чагында һәм авырганда син безнең өчен борчылгансың, беренче тапкыр балалар бакчасына, мәктәпкә баргандa дулкынлангансың. Хәзер инде без үстек, гаилә кордык, ә син һаман безнең өчен кайгырасың.

Әниебез Фәүзәнә Фәүзел кызы 1968 елның 13 октябрендә Тархан авылында Фәүзел һәм Фәнзилә Хурамшиннар гаиләсендә уртанчы бала булып дөньяга килә. Ул Шаран урта мәктәбен тәмамлый, ә аннары Бакалы авылы 178 санлы һөнәр техник училищесында бухгалтерлыкка укый. Шаран районара механикалаштырылган күчмә колоннасында бухгалтер булып эшли, 1989 елда авылдашы, әтиебез Илгизәр Галинур улы Фәрхетдиновка кияүгә чыга. Аннары әни Шаран авылында универмагка сатучы булып эшкә урнаша, 1999 елда гаиләбез район үзәгенә күченә. Әни 20 ел



*Фәүзәнә Фәрхетдинова.*

сәүдә өлкәсендә хезмәт куя. 2007 елда үз эшен башлап җибәрә, вакыт үтү белән кибетләре дә ачыла. Хәзерге вакытта Шаран авылында дүрт кибете һәм стационар булмаган өч сәүдә үзәге эшли.

Әти-әниебезгә язмыш бүләге булып уллары Азат, аннары мин – кызлары Гөлназ дөньяга килгәнбез. Әти-әниебез безне үз үрнәкләрендә игелекле, ярдәмчел һәм эшсөяр итеп тәрбияләделәр, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, гаиләдә татулык һәм иминлек сакларга өйрәттеләр. Алмаз үзенең гаиләсе белән Туймазы шәһәрендә яши, тормыш иптәше Лилия белән бергә уллары Камилне тәрбиялиләр. Абый "Башнефть-добыча" җәмгыятендә мастер булып эшли. Мин әлеге вакытта әнигә эшкуарлык эшчәнлегендә ярдәм итәм. Ирем М. елдан артык махсус хәрби операция зонасында хезмәт итә. Әниебез актив һәм юмарт хәйрияче, Шаран районында мәдәни һәм спорт чараларында иганәче генә түгел, ул шулай ук якташларыбызга – махсус хәрби операциядә катнашучыларга да ярдәм итә.

Әнием – ягымлы, позитив кеше, ул бик игелекле һәм мәрхәмәтле. Ул кешеләрдә гаделлек һәм ышанычлылык кебек сыйфатларны хөрмәт итә, чөнки ул үзе дә шундый. Иртәдән кичкә кадәр әти белән әни кибетләрен сыйфатлы товарлар белән тәэмин итү, сатып алучыларга уңайлы булсын өчен эшлиләр, алар 34 ел бергә тату яшиләр. Әниебезнең өйгә, гаиләгә вакыты һәм көче дә калмый кебек. Юк, алай түгел, ул барысына да өлгерә! Көндәлек мәшәкатьләр арасында әни бакчада һәм өйдә чәчәкләр үстерергә дә вакыт таба, үзенчәлекле савыт-саба сатып алырга һәм өйне матурларга ярата.

Мин әниемне яратам һәм аның эшкә сәләтенә һәм максатчанлыгына сокланам. "Хатын-кыз – ел директоры" Бөтенрусия конкурсының төбәк этабында ул "Югары җитәкчелек осталыгы" номинациясендә җиңүче булды, шулай ук әниебез "Хатын-кыз – милләт анасы" Бөтенрусия конкурсының төбәк этабында да номинациядә җиңүче булып танылды.

Әниебез районда эшкуарлык эшчәнлеген үстерүдә актив катнаша, үзенең нәтиҗәле хезмәте белән кече туган илебезнең социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертә. Быел аны Шаран районы Хатын-кыз эшкуарлар ассоциациясе рәисе итеп сайладылар. Һәм ул әлеге җәмәгать эшен дә бик яхшы башкара.

Шндый инде ул безнең әниебез – яхшы җитәкче, искиткеч хатын, ягымлы дәү әни, тугры ахирәт һәм уңган хуҗабикә.

Чираттагы көз аның юбилей көзе. Әни, әнкәем! Сине чын күңелдән матур юбилееӊ белән котлыйбыз! Сиңа нык лы сәламәтлек, эшеңдә уңышлар, гаилә иминлеге, яхшы хәбәрләр һәм матур бүләкләр телибез! Без сине бик яратабыз!

*Фәрхетдиновлар гаиләсе исеменнән кызың ГӨЛНАЗ.*
*Шаран авылы.*
*Фото гаилә альбомыннан алынды.*

• СОЦИАЛЬ СӘЯСӘТ

# Изгелек һәм җылылык атмосферасында

Уфада II Бөтенрусия "Киртәләрне җиңеп" форум-күргәзмәсе үтте

***Әлеге әһәмиятле вакыйга инвалидлар, шулай ук алар белән эшләүче белгечләр өчен зур мәгънәгә ия.***

Беренче көнне Шаран районынының зур делегациясе "Торатау" Конгресс-холлында форум-күргәзмәдә булды, аның составында Шаран районы муниципаль район хакимияте башлыгы урынбасары Гүзәл Аксанова, муниципаль район хакимияте төзелеш һәм архитектура бүлеге начальнигы вазифаларын башкаручы Светлана Сарычева, Шаран үзәк район дәваханәсе дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методисты Гүзәлия Хәбирова, Шаран авылы "Теремок" балалар бакчасы мөдире Элеонора Некрытова, Шаран авылы "Батыр" балалар бакчасы мөдире вазифаларын башкаручы Зөлфия Муллагалиева, Шаран авылы "Радуга" балалар бакчасы укытучы-логопеды Гөлназ Идиятова, 1 санлы Шаран мәктәбе социаль педагогы Айгөл Сәлимова, район инвалидлар җәмгыяте җитәкчесе Равилә Галиуллина, район мәгариф бүлеге методисты Алевтина Хәбибуллина һәм Яшьләр үзәге педагог-психологы Альбина Гыйниятова булды.

"Киртәләрне җиңеп" форумында катнашучыларны БР Башлыгы Радий Хәбиров исеменнән БР Башлыгы Хакимияте җитәкчесе Максим Забелин сәламләде. БР гаилә, хезмәт һәм халыкны социаль яклау министры Ленара Иванова катнашында пленар өлеш, семинар, төрле мастер-класслар, модалар күрсәтү, тематик "түгәрәк өстәлләр" булды. Теләүчеләр өчен – республика медицина оешмалары табибларының, шулай ук министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре консультацияләре, тернәкләнү өлкәсендә җиһазлар һәм хезмәтләр экспозицияләре күргәзмәсе, уникаль товарлар һәм кул эшләреннән республика хәйрия ярминкәсе, тауга үрмәләү, җилкәнле катамаран төзелеше буенча осталык дәресләре, логозона – балалар сөйләмен үстерү буенча диагностика һәм консультацияләр, күрмәүчеләр һәм начар күрүчеләр өчен крайәйберләре, табигый сабын, шәмнәр, блокнотлар кешеләрнең игътибарын җәлеп итте. Күргәзмәдән беркем дә туганнары һәм якыннары өчен бүләксез китмәде.




*Шаран районыннан форумда катнашучылар.*

Делегатларыбызга башкорт тирмәсе дә бик ошады, биредә күрмәүчеләр һәм начар күрүчеләр ны өйрәнү басмаларын презентацияләү һәм башка күп нәрсәләр. Форум-күргәзмәдә Русиянең 12 төбәгеннән 50 компания катнашты.

Форумда катнашучыларның һәркайчы үзләре өчен кызыклы һәм файдалы нәрсәләр таба алдылар. Шаран районыннан катнашучыларга республиканың төрле үзәкләре, инвалидлар өчен приютлар һәм интернатлар тәрбияләнүчеләренең кул эшләре күргәзмәсе аеруча ошады. Начар күрүче осталар куллары белән ясалган бәйләм уенчыклар, төрле бизәнгечләр һәм кием аксессуарлары, көнкүреш өчен махсус адаптацияле төсле китаплар күрсәтелде. Картиналар галереясы да соклангыч булды, монда күренекле рус рәссамнарының картиналары күрмәүчеләр һәм начар күрүчеләр өчен яраклаштырылган. Киләчәктә форумда әниләре белән бергә "үзенчәлекле" балалар да актив катнашсыннар иде. Изгелек һәм яктылык атмосферасында алар үзләре өчен күп яхшы нәрсәләр табачаклар. Форумда беркемгә дә киртәләр юк!

*Маргарита ӘХМӘТОВА, делегация әгъзасы.*
*Фото ачык чыганаклардан алынды.*

• СӘЛАМӘТЛЕГЕГЕЗНЕ САКЛАГЫЗ!

# Гриппка каршы прививка ясатыгыз!

Шаран районында гриппка каршы прививка ясау кампаниясе дәвам итә

***Узган атнада Шаран районында кискен респиратор авыруларның 76 очрагы теркәлде, аларның 19ы балаларда. 4 меңнән артык кеше прививка ясатты, бу халыкның 24%ын тәшкил итә.***

Вакцинация үзебезнең илдә җитештерелгән "Совигрипп" һәм "УльтриксКвадри" вакциналары белән үткәрелә. Гриппка каршы прививканы поликлиникаларда, яшәү урыны буенча фельдшерлык пунктларында, эш урыны буенча күчмә прививка бригадалары оештырылганда, яисә әлеге эшчәнлек төренә рөхсәте булган медицина үзәкләрендә ясатырга мөмкин. Учреждение җитәкчеләренә коллективларда гриппка каршы вакцинация оештыру кирәклеге турында хәбәр итәбез.

Вакцина кеше организмында авыру барлыкка китерми. Гриппка каршы вакцинация процессында организмга антигенлы инактивлаштырылган вирус кисәкчекләре кертелә. Организмга вирус антигеннары кертү организмны антитәнчекләр барлыкка китерүгә стимуллаштыра, алар канда бер елга кадәр саклана. Шуңа күрә организмга вирус эләккәндә, алдан эшләнгән антитәнчекләр вирус белән бәйләнешкә керәләр һәм вирус таралуга юл куймыйлар.

Хөрмәтле район халкы! Үзегезнең һәм якыннарыгызның гомерен һәм сәламәтлеген саклагыз, гриппка каршы прививка ясатыгыз!

*А. ГАЙНАНОВА, "Роспотребнадзор"ның Башкортстан Республикасы буенча идарәсе Туймазы территориаль бүлеге начальнигы.*

## КОТЛЫЙБЫЗ!



Шаран авылында яшәүче сөекле тормыш иптәшем, әниебез, дәү әниебез **Гөлфирә Нуриәхмәт кызы Әхмәдиеваны** матур юбилее белән чын йөрәктән кайнар котлыйбыз!

*Сөекле карашың кояшка тиң —*
*Бар тормышны нурга күмәсең.*
*Бу дөньяның барлык хикмәтләрен*
*Бары тик син генә беләсең.*
*Тормышта гел ярдәм итеп тора*
*Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең;*
*Иркәлисең, яратасың, юатасың,*
*Тыңлыйсың да, аңлыйсың да үзең.*
*Сәламәтлек, озын гомер язсын,*
*Гел көләч һәм яшь бул хәзергечә!*
*Көннәрең синең кутәренке булсын,*
*Сөенеп һәм сөендереп мең-мең яшә!*

***Ихлас теләкләр белән тормыш иптәшең, балаларың һәм оныкларың.***

● УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

## Акмулла һәйкәле янында

Коя каен яфракларын салкын җилдә,
Шул чакларда моңсуланам мин дә.
Искә төшә Акмулланың шигырьләре,
Эз калдырып бу дөньядан китүләре.
Коелсын ла яфраклары... каен кала,
Язлар белән каен-горур яңарала,
Көзләрендә туфрагына яфрак җәя.
Тамыр шуннан көч ала дип, бирәм бәя.
Килдем бүген сөйләшергә һәйкәлеңә,
Тирә-ягың көзен сулмас чәчкә генә.
Синең алда, күрәсеңдер, Башкортстан!
Чәчкәләрнең таҗларында иҗади дан.
Алты яшьтән ятим калып яшәсәң дә,
Ачлы-туклы, белем алып мәдрәсәдә.
Өч милләтне бердәм илттең яктылыкка,
Комсызларны ала бардың җәя-укка.
Халкың йөрәгендә синең үгет-нәсер,
Укыгыз, башкортларым!.. Үссен нәсел!
Аң-белемле, көч-куәтле, үрнәкле дә,
Яшәр өчен аңлы булу кирәкле лә.
Акмулла син, Хакмулла ул! Сау бул, димен,
Сөйләштек тә, серләштек тә икәү бүген...
Сүнмәс кояш булып яктырттың син
Башкортстан иленең күген.
Алтын яфрак өсләреннән басып үтәм,
Яттан укыйм шигыреңне адым белән.
Синең белән сөйләшүдән илһам алам,
Ачылмаган серләрең күп, тагын килә м!

***Сәдинә ВӘЛИЕВА.***
***Шаран авылы.***

## Яшәп туймас дәртем бар

Күңелемдә чишмә җыры,
Моңнар тулы хисләр бар.
Тормышыма ямь өстәргә,
Мәңге уңмас төсләр бар.
Йөрәгемдә ялкын сүнмәс,
Яшәп туймас дәртем бар.
Гадел булу, дөрес яшәү,
Шундый таләп, шартым бар.
Бу тормышка гашыйк булып,
Яратырлык көчем бар.
Иңнәрне иңнәргә терәп,
Таянырлык кешем бар.

## Тормыш - сынау

Кеше хәлен кемнәр аңлый.
Минем хәлем үземдә.
Яшим үземнең хәл белән
Сабырлыкта, түземдә.
Кыен хәлдән чыгу юлын
Үзең генә беләсең.
Тик белмисең авырлыкның
Кайдан, ничек киләсен.
Тормыш сыный, үзе кыйный,
Сукмагыннан үткәндә.
Сынып сыгылмаганнарны
Хөрмәтли ул киткәндә.
Кем түзәлми кырыс җилгә
Тормыш эзе күмелә.
Җыры кала тәмамланмый,
Кинәт кенә өзелә.
Сынауларның чиге юктыр,
Яшәү ул үзе сынау.
Кешелеклелек сыйфаты –
Авыр сынауда сынмау.

***Фирдат ВӘЛИЕВ.***
***Иске Теләүле авылы.***


Гидронасосы: НШ 10, 32, 50, 100
Гидрораспределители
ОПТОМ И В РОЗНИЦУ В УФЕ
*Приглашаем к сотрудничеству магазины
+7 987 132 97 01
Скажи слово «ГАЗЕТА» и получи скидку 5%*
Торговый дом МЗПО
td-mzpo.ru
*Подробности уточняйте по телефону у консультантов
Реклама

ТРЕБУЮТСЯ:
ДЛЯ РАБОТЫ ВАХТОВЫМ МЕТОДОМ В Тюмени и Тюменской области
РОСНЕФТЬ ГАЗПРОМ НЕФТЬ
ВОДИТЕЛИ кат. В, С, Е/ В,С + ДОПОГ
ВОДИТЕЛИ ПОГРУЗЧИКА
МАШИНИСТЫ крана автомобильного, бульдозера, экскаватора
СТРОПАЛЬЩИКИ
Проезд, питание, медкомиссия за счет компании.
Комфортные условия проживания.
8 922 658 78 88
ОГРН 1068605062395
Реклама

В Центральной аптеке № 76
(с. Шаран, ул. Центральная, 19)
31 октября с 14.00 до 15.00 ч.
“РАДУГА ЗВУКОВ”
СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ
аналоговые, цифровые
Цена: от 10 000 до 25 000 руб. (Россия, Дания, Германия)
(цена зависит от мощности слухового аппарата)
Справки и заявки на дом
по тел. 8-901-866-81-57
Сдайте один старый аппарат и получите скидку при покупке нового аппарата 7 %
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, необходима консультация специалиста
РЕКЛАМА. ИП Вилков В. А. ОГРН 304183133700096.

Екатеринбург шәһәренә вахта ысулы белән
КУХНЯ ЭШЧЕЛӘРЕ ТАЛӘП ИТЕЛӘ,
эш хакы аена 60000 сум,
яшәү урыны бирелә.
Тел.: 8-982-717-49-71.
РЕКЛАМА. ОГРНИП 307662330400047.

Юдыру белән
СУ СКВАЖИНАЛАРЫ
бораулыйбыз.
Скважиналарны чистартабыз.
Тел.: 8-927-344-93-70, 8-917-483-50-93.
РЕКЛАМА.ШЭ Р.М. Зарипов. ОГРН 313028000058844.

Автомобильләр
сатып алам.
КЫЙММӘТ.
Тел.: 8-937-482-40-06.
РЕКЛАМА. ОГРН 31402800092214.

√ Профнастил
√ Металлопрокат
√ Пиломатериаллар
√ Керамзитблоклар
Чакмагыш авылы, Ленин урамы, 23, “Домино” кибете.
Тел.: 89191446891, 89196048557.
(сәүдә офисы һәм склад бер урында).
РЕКЛАМА. ОГРН 321028000051125.

Һәрвакыт сатуда ВАК ТАШ, КОМ, СОРТИРОВКА (коелар өчен), КЫЗЫЛ БАЛЧЫК, ЯРЫЛГАН УТЫН. «КамАЗ», «ЗиЛ» а/м китереп бирәбез. Тел.: 8-927-321-39-46, 8-917-495-86-62, 8 (34769) 2-56-75 (өйнеке).
РЕКЛАМА. ШЭ Д. Н. Закиров. ОГРН 307026914500020.

8-963-902-0000 http://okna-bahetle.ru
ОКНА «Бәхетле»
5 -ое окно в подарок
●Расширение оконного проема
●Установка откосов
●Рулонные шторы
●Жалюзи
Только у нас:
Отлив, подоконник, москитная сетка, замер БЕСПЛАТНО
скидка до 30%
до 31.10.2023 г.
РАССРОЧКА БЕЗ УЧАСТИЯ БАНКА

ТЕПЛИЦЫ
• усиленный каркас
• две двери, две форточки
• поликарбонат 4мм с УФ-защитой
• БЕСПЛАТНАЯ доставка и установка!
• ГАРАНТИЯ!
Успейте заказать теплицу по выгодным ценам!
тел: 8 927 348-24-30
ЗАВОД ТЕПЛИЦ «НАРОДНЫЙ»
ОГРН 317028000142318 ИП Мустафин Р.М. Реклама.

Түбән бәяләр буенча төсле металлдан
ТӘРӘЗӘ ЙӨЗЛЕКЛӘРЕ.
Тел.: 89274353542, 89046077265.
РЕКЛАМА. Үзмәшгуль И. П. Харисов. ИНН 164702436580.

ПРОФНАСТИЛ, САЙДИНГ
МЕТАЛЛОЧЕРЕПИЦА, ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ
СКИДКА ОТ КОЛИЧЕСТВА ОБЪЕМА
ГАРАНТИЯ НИЗКИХ ЦЕН!
село Шаран ул. Торговая 3/7
+7(927)-952-38-49
ИП Гусманов Д. М. ОГРН 321028000130339. РЕКЛАМА. Подробности у консультанта.





Тере килеш
СЫЕР МАЛЛАРЫ*
(ҮГЕЗЛӘР, СЫЕРЛАР, ТАНАЛАР)
САТЫП АЛАМ.
Тел.: 8-927-237-31-49.
РЕКЛАМА. ШЭ И. И. Муллагалиев. ОГРН 314028000126329.


## САТЫП АЛАМ:

***сыерлар, бозаулар, атлар, сарыклар, йон*. Телефоннар: 8-917-248-57-22, 8-917-283-71-05;***

* * *

***каз мамыгы, килограммы 500 – 600 сумнан. Яңа. Мендәрләр һәм ястыклар. Телефон: 8-937-311-80-72.***

## САТЫЛАЛАР:

***бозаулар*.***
***Тел.: 8-937-600-37-65.***

## ОНЫТМЫЙБЫЗ



1 ноябрьдә сөекле кызыбыз, хатыным, әниебез, дәү әниебез, апаебыз, апабыз Тимеркәева Илмира Тимергали кызының йөрәге тибүдән туктаганга бер ел була.

Ул бик игелекле, тормыш сөючән, зирәк, тырыш, ярдәмчел, хезмәт сөючән кеше иде. Аны кире кайтарып булмый, әмма онытырга мөмкин түгел.

*Каберләрең нурлар белән тулсын,*
*Рухыңны шатлык бизәсен.*
*Безнең өчен син һаман да исән,*
*Күктән кояш булып көләсең.*
*Күз алдыбызда торасыңдыр кебек*
*Күзебезне азга йомсак та.*
*Изге булганың өчен, Ходаем,*
*Урының булсын синең оҗмахта.*
*Изгеләрдән-изге кеше булдың,*
*Үрнәк идең җирдә кулләргә.*
*Фәрештәләр изге исемеңне*
*Күтәрсеннәр зәңгәр күкләргә.*

Белүчеләр аны җылы сүзләр белән искә алсыннар иде. Онытмыйбыз, яратабыз, юксынабыз.

***Әтисе, әнисе, ире, балалары, туганнары.***

*Гамәлдәге закон таләпләренә ярашлы барлык төр терлекләрне һәм терлекчелек продукциясен күчереп йөртү ветеринария документлары буенча дәүләт ветхезмәте контроле астында тормышка ашырылырга тиеш.


Оештыручылар: Башкортстан Республикасы Матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат чаралары агентлыгы, “Башкортстан Республикасы” нәшрият йорты Башкортстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе.

**Баш мөхәррир ХӘМӘДИЕВА М. Ф.**

ПИ № ТУ02-01353нче теркәү таныклыгы Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм киңкүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Башкортстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2015 елның 10 июлендә бирелде.

Телефоннар:
мөхәррир - 2-14-08
җаваплы секретарь - 2-24-36
хатлар бүлеге - 2-22-37
хәбәрчеләр, дубляж бүлеге - 2-20-36
реклама кабул итү - 2-24-09

Гәзит атна саен җомга көнендә татар телендә чыга. Реклама һәм белдерүләр эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы. Редакциянең фикере авторлар фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Теге яки бу хатны, материалны басу-басмау мәсьәләсен редакция үзе хәл итә. Редакция барлык хатларга да җавап бирми. Кульъязмалар кире кайтарылмый. Аноним хатлар бастырылмый һәм тикшерелми.

E-mail: xamadeeva.m@rbsmi.ru

Редакциянең адресы: 452630, Башкортстан Республикасы, Шаран районы, Шаран авылы, Үзәк урам, 14.

Нәшер итүченең адресы: 450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13.

Гәзит редакциядә җыела һәм биткә салына, офсет ысулы белән җыела. “Башкортстан Республикасы” нәшрият йорты Башкортстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе филиалы - Октябрьский мәгълүмат үзәгендә (452620, Башкортстан Республикасы, Октябрьский шәһәре, Чапаев урамы, 18) басыла.

“Шаран киңлекләре”, №43 (10117), 2023. Бәясе ирекле. Тиражы 288 данә. Язылу индексы 50652. Кул куелды: 26.10.23 ел. 13.00 сәгатьтә (график буенча - 13.00 сәгатьтә). Заказ № 2600